Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

27 март, 2024 ел №9

**Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Купка авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 7 апреленә 11 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Купка авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын һәм 2024 елның 7 апреленә 17 сәгать 00 минутка икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Купка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, I төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәр 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Купка авылы урамнарында юлларны вак таш җәеп ремонтлау һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Купка авылында урам-юл челтәрен карап тоту, (шартнамә буенча түләү);
- Купка авылы чишмәсе территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Купка авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Купка авылы урамнарына асфальт җәю, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру,
- Купка авылында артезиан скважиналары өчен тирәннән суыртү насосы сатып алу һәм су белән тәэмин итү челтәрен күчереп салу;
- Купка авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);
- Купка авылында зиратларны коймалау, материал сатып алу һәм җирләү урыннарын карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Купка авылына су алу өчен урнаштырылган коеларны ремонтлау һәм чистарту;
- Купка авылында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау;
- алга таба Купка авылында су скважинасы бораулау өчен, скважина бораулауга проект-смета документларын эшләү

2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

урам яктыртуны ясау (Купка авылында урам яктыртуны көйләү өчен урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу);

су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Купка авылында артезиан скважиналары өчен тирәннән суырту насосы сатып алу һәм су белән тәэмин итү челтәрен күчереп салу; алга таба Купка авылында су скважинасы бораулау өчен, скважина бораулауга проект-смета документларын эшләү);

җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Купка авылы чишмәсе территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Купка авылында янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы комплектлау

материаллары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машинаны тоту (ягулык-майлау материалларына чыгымнар, транспорт йөртүчене тоту);

коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; (Купка авылына су алу өчен урнаштырылган коеларны ремонтлау һәм чистарту);

һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаганнары) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Купка авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәлне ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Купка авылы урамнарында юлларны вак таш җәеп ремонтлау һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Купка авылы урамнарына асфальт җәю, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Купка авылында урам-юл челтәрен карап тоту);

торак пункт территориясен төзекләндерү (Купка авылында яссы спорт корылмаларын төзү һәм булганнарын ремонтлау; Купка авылында балалар уен мәйданчыкларын карап тоту һәм ремонтлау; Купка авылы территориясендә үләнне чабу);

традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Купка авылында зиратларны коймалау, материал сатып алу һәм җирләү урыннарын карап тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы Ф.М. Фәттахов

ОГРН 1051607753233
ИНН 1623001727